РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2024 Буа шәһәре № 125/Бк-к

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы
белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган
гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 февралендәге 100 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Буа муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә, ТР Буа муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 9 сентябрендәге 404-п номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә ( 23.01.2014 №10-п, 26.03.2014 №125-п, 2.10.2015 №533-п, 27.10.2015 №538-п, 05.05.2016 №189-п, 06.03.2017 №88-п, 11.01.2018 №3-п, 22.08.2019 №357/ик-п, 07.03.2021 №54/Бк/к, 25.05.2021 №136/Бк/к, 14.03.2024 №66/Бк/к карарлары ред.), алга таба-Тәртип), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. Тәртипнең 1.3 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«1.3 Компенсация алу хокукын билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 03.12.2019 елның 1095 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 февралендәге 100 номерлы үзгәрешләр белән расланган кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Түләүне билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме түләүне билгеләү турында гариза бирү аена кадәрге соңгы 12 календарь айның гаилә әгъзаларының керем суммасыннан чыгып исәпләнә.»

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш http://buinsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов